**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 16 май № 351

г. Казань

Татарстан Республикасының урта һөнәр белеме бирү программаларын тормышка ашыручы һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны дуаль укытуны оештыру һәм үткәрү тәртибен раслау турында

Һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның һөнәр белемен һәм һөнәри күнекмәләрен үстерү, урта һөнәри белемнең һөнәр белеме бирү программаларын тормышка ашыруның челтәр формасын оештыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасының урта һөнәр белеме бирү программаларын тормышка ашыручы һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны дуаль укытуны оештыру һәм үткәрү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына әлеге карарның үтәлеше барышы турында ел саен 15 декабрьгә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына мәгълүмат тапшырырга.

3. Татарстан Республикасының урта һөнәр белеме бирү программаларын тормышка ашыручы һөнәри белем бирү оешмаларының гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләренә Татарстан Республикасының урта һөнәр белеме бирү программаларын тормышка ашыручы һөнәри белем бирү оешмаларында укуның йөреп уку формасында укучыларны дуаль укытуны оештыру һәм үткәрү буенча чаралар башкарырга.

4. Татарстан Республикасы оешмалары җитәкчеләренә дуаль укытуны оештыру һәм үткәрү буенча чараларда катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\351.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 16 май, 351 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасының урта һөнәр белеме бирү программаларын тормышка ашыручы һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны дуаль укытуны гамәлгә ашыру тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының урта һөнәр белеме бирү программаларын тормышка ашыручы һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны (алга таба – Укучылар) дуаль укытуны гамәлгә ашыру тәртибе барлык оештыру-хокукый формадагы һәм милек формасындагы хуҗалык итүче субъектларның агымдагы һәм киләчәктәге ихтыяҗларын исәпкә алып, төбәк хезмәт базарында кадрларга һәм белгечләргә сорауның һәм тәкъдимнең тигезлегенә ирешеү, шулай ук Татарстан Республикасының урта һөнәр белеме бирү программаларын тормышка ашыручы һөнәри белем бирү оешмалары һәм Татарстан Республикасының хуҗалык итүче субъектлары, муниципаль берәмлекләре арасында социаль партнерлык һәм үзара бәйләнешләр механизмнарын үстерү максатларында эшләнде.

Әлеге Тәртип барлык оештыру-хокукый формадагы һәм милек формасындагы Татарстан Республикасы оешмаларында (алга таба – Предприятие) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары карамагында булган Татарстан Республикасының урта һөнәр белеме бирү программаларын тормышка ашыручы һөнәри белем бирү оешмалары тарафыннан (алга таба – Белем бирү оешмасы) урта һөнәри белемнең һөнәр белеме бирү программаларын (алга таба – УҺБ ҺБП) үзләштерүче укуның йөреп уку формасында укучыларны дуаль укытуны гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Тәртипнең көче урта һөнәри белемнең дәүләт белем бирү стандартлары һәм федераль дәүләт белем бирү стандартлары (алга таба – УҺБ ФДБС) һәм укыту дисциплиналары һәм һөнәри модульләрнең эш программалары нигезендә УҺБ ҺБП тормышка ашыручы Белем бирү оешмаларына тарала.

1.3. Дуаль укыту дигәндә әлеге Тәртиптә УҺБ ҺБП белән каралган укытуны, уку һәм производство практикасын үткәрүне һәм укыту эшчәнлегенең башка төрләрен башкаруны гамәлгә ашыру өчен кирәкле ресурслары булган Предприятиеләр, Белем бирү оешмалары һәм бүтән оешмаларның үзара бәйләнешләренә нигезләнгән УҺБ ҺБП тормышка ашыруның челтәр формасы күздә тотыла.

1.4. Дуаль укыту Белем бирү оешмасы Предприятие белән берлектә эшләнә һәм раслана торган һәм түбәндәгеләрне күздә тоткан программа нигезендә тормышка ашырыла:

1.4.1. УҺБ ФДБС төп таләпләрен үтәүне тәэмин итү.

1.4.2. Укучыларның Предприятие базасында һәм Белем бирү оешмасы базасында укуын берләштерү.

1.4.3. Укучыларның эшче һөнәре (белгечлеге) буенча һөнәри компетенцияләре формалашу белән бергә гамәли тәҗрибә дә алуы.

1.5. Предприятие белән килештереп, Белем бирү оешмасы эшләгән дуаль укыту программасы түбәндәгеләрне күздә тотарга тиеш:

1.5.1. Укучыларда УһБ ФДБС һәм укыту дисциплиналары һәм һөнәри модульләрнең эш программалары нигезендә эшче һөнәре (белгечлеге) буенча гомуми һәм һөнәри компетенцияләре формалашуын;

1.5.2. УһБ ФДБС нигезендә УһБ һБП модульләре эчтәлеген исәпкә алып, Укучыларның гамәли тәҗрибәгә ия булуы.

1.6. Дуаль укыту программасы УһБ ФДБС үтәүне тәэмин итү шартларында дуаль укыту программасында билгеләнә торган көннәр (атналар, айлар) буенча Предприятие һәм Белем бирү оешмасы базасында укытуны берләштерүне күздә тота.

1.7. Укучыларда УһБ ФДБС һәм укыту дисциплиналары һәм һөнәри модульләрнең эш программалары нигезендә эшче һөнәре (белгечлеге) буенча гомуми һәм һөнәри компетенцияләре формалашуы, шулай ук УһБ ФДБС нигезендә УһБ һБП модульләре эчтәлеген исәпкә алып, Укучыларның гамәли тәҗрибәгә ия булуы Белем бирү оешмасы тарафыннан дуаль укытуны оештыруның төп максаты булып тора.

1.8. Предприятиеләрдә Белем бирү оешмасы Укучыларын укытуны оештыру һәм үткәрүнең төп бурычлары:

1.8.1. Белгечлеге (һөнәре) кысаларында Укучыларның һөнәри эшчәнлекнең бөтен төрләрен комплексды үзләштерүе, гомуми һәм һөнәри компетенцияләре формалашуы, УһБ ФДБС һәм укыту дисциплиналары һәм һөнәри модульләрнең эш программалары нигезендә кирәкле осталыклар һәм гамәли эш тәҗрибәсе алу;

1.8.2. һБП Белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның һөнәри әзерлек дәрәҗәсен сыйфатлы яхшырту;

1.8.3. Координацияләү һәм Белем бирү оешмаларының укыту-җитештерү эшчәнлеген Предприятиедәге җитештерү шартларына җайлаштыру.

1.9. Белем бирү оешмалары һәм Предприятиеләр Укучыларны дуаль укытуны оештыру һәм үткәрү өчен законнар нигезендә җаваплы була.

## II. Татарстан Республикасының урта һөнәр белеме бирү программаларын тормышка ашыручы һөнәри белем бирү оешмаларында Укучыларны дуаль укытуны оештыру һәм үткәрү

2.1. Дуаль укытуны тормыша ашыру Белем бирү оешмалары тарафыннан түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

2.1.1. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары;

2.1.2. Әлеге Тәртип;

2.1.3. Белем бирү оешмаларында һәм Предприятиеләрдә гамәлдә булган дуаль белем бирү турында нигезләмәләр, дуаль укыту программасы, һөнәр (белгечлек)

буенча укыту эш планы, еллык календарь график, белем бирү процессын тәэмин итү буенча чаралар планы, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы, Белем бирү оешмалары һәм Предприятиеләр боерыклары;

2.1.4. Предприятиеләр һәм Белем бирү оешмалары арасында төзелгән дуаль укытуны оештыру турында шартнамәләр. Әлеге Тәртип белән күрсәтелгән шартнамәне әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтага ярашлы форма буенча төзергә тәкъдим ителә;

2.1.5. Законнар нигезендә Укучылар һәм Предприятиеләр арасында төзелгән дуаль укыту турында укучы шартнамәләре. Әлеге Тәртип белән күрсәтелгән шартнамәне әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтага ярашлы форма буенча төзергә тәкъдим ителә.

2.2. Дуаль укытуны оештыру һәм үткәрү максатларында Белем бирү оешмасы:

2.2.1. Дуаль укыту турында нигезләмәне эшли һәм раслый;

2.2.2. Ел саен, агымдагы елның 1 августына кадәр Предприятие белән дуаль укытуны оештыру турында шартнамә төзи һәм имзалый (килешү буенча). Әлеге Тәртип белән күрсәтелгән шартнамәне әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтага ярашлы форма буенча төзергә тәкъдим ителә;

2.2.3. Предприятие белән берлектә дуаль укыту программасын, һөнәр (белгечлек) буенча укыту эш планын, еллык календарь графигын, белем бирү процессын тәэмин итү буенча чаралар планын эшли һәм раслый;

2.2.4. Предприятие белән дуаль укыту өчен предприятиегә җибәрелгән Укучылар вакытын, санын һәм исемлек составын килештерә;

2.2.5. Укучы һәм Предприятие арасында дуаль укыту турында укучы шартнамәләрен төзүдә ярдәм итә;

2.2.6. Дуаль укытуны оештыру турында, Укучыны Предприятиегә җибәрү турында һәм, Предприяте белән килештереп, Укучыларның һәр төркеменә кураторлар (производствода укыту осталары яки укытучылар) билгеләү турында боерыклар чыгара;

2.2.7. Дуаль укытуны оештыру турында һәм шартнамә һәм дуаль укыту программасы белән билгеләнгән өлешендә үз базасында дуаль укыту программасын тормышка ашыруны тәэмин итә;

2.2.8. УһБ ФДБС, уку планы һәм дуаль укыту программасы нигезендә Укучы тулы күләмдә белем алсын өчен; студент квалификация имтиханын уңышлы тапшырган очракта квалификация дәрәҗәсе турында документ (таныклык) бирү өчен (әгәр УһБ ФДБСдә һөнәри эшчәнлек төрләренең берсе кысаларында УһБ ҺБП модулен өйрәнү нәтиҗәләре буенча эшче һөнәрен үзләштерү каралган булса) законнар нигезендә җаваплы була;

2.2.9. Дуаль укыту барышында Предприятиедә гамәлдә булган эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре, хезмәтне саклау, яшәү иминлеге һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләре һәм Предприятиедә гамәлдә булган бүтән локаль актлар, Предприятие милкеннән файдалану буенча таләпләр Укучы тарафыннан саклануы өчен законнар нигезендә җаваплы була;

2.2.10. Производствода укыту остасы, укытучы, остазның Предприятиедә укыту процессына һәм җитештерү процессына кагылышлы күрсәтмәләрен Укучы тарафыннан үтәлүен тәэмин итә;

2.2.11. Үзенә бирелгән вәкаләтләр кысаларында кураторга (производствода укыту остасы яки укытучы) УҺБ ФДБС, дуаль укыту программасын, уку дисциплиналарының һәм һөнәри модульләрнең эш программаларын, вазыйфаи тәгълимнамәләр һәм бурычларны (шул исәптән үткәрелгән дәресләрне исәпкә алу журналын тутыру, Укучы көндәлеген алып баруны контрольдә тоту, Укучының өлгереше хакында мәгълүматларны гамәли дәресләр журналына системалы рәвештә теркәп бару буенча) тормышка ашыруны тәэмин итәргә ярдәм итә;

2.2.12. Предприяте белән берлектә дуаль укыту процессында Укучы үзләштергән УҺБ ФДБС һәм уку дисциплиналарының һәм һөнәри модульләрнең эш программалары нигезендә эшче һөнәре (белгечлеге) буенча гомуми һәм һөнәри компетенцияләрен бәяләү процедурасын оештыра;

2.2.13. Укучыны йомгаклау аттестациялəвендә дуаль укыту программасын үзләштерү нәтиҗәләрен исәпкә алуны тәэмин итә;

2.2.14. Белем бирү оешмасының гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте вәкаләтле органына агымдагы елның 15 ноябренә кадәр Предприятие белән килештерелгән узган уку елына дуаль укыту үткәрү турында еллык хисап тапшыра.

2.3. Дуаль укытуны оештыру һәм үткәрү максатларында Белем бирү оешмасы (килешү буенча):

2.3.1. Дуаль укыту турында нигезләмәне эшли һәм раслый;

2.3.2. Ел саен, агымдагы елның 1 августына кадәр Белем бирү оешмасы белән дуаль укытуны оештыру турында шартнамә төзи;

2.3.3. Белем бирү оешмасы белән берлектә дуаль укыту программасын, һөнәр (белгечлек) буенча укыту эш планын, еллык календарь графигын, белем бирү процессын тәэмин итү буенча чаралар планын эшли һәм раслый;

2.3.4. Дуаль укыту үткәрү вакытын һәм дуаль укытуга җибәрелгән Укучыларның исемлек составын килештерә;

2.3.5. Белем бирү оешмасы белән килештерелгән санда һәм вакытта Укучыларны укытуга кабул итә;

2.3.6. Законнар нигезендә Укучылар белән дуаль укыту турында укучы шартнамәләре төзи. Әлеге Тәртип белән күрсәтелгән шартнамәне әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтага ярашлы форма буенча төзергә тәкъдим ителә.

2.3.7. Укучыларны эчке тәртип кагыйдәләре, санитар, янгынга каршы һәм бүтән гомуммәҗбүри нормалар һәм кагыйдәләр белән; конкурс нигезендә Предприятиедән белем алу заемын (ул булганда) алу шартлары белән; Предприятиегә эшкә урнашу мөмкинлекләре белән таныштыра;

2.3.8. Укучыларны дуаль укыту программаларының һәр юнәлеше буенча гамәли белемнәргә һәм алымнарга өйрәтү өчен аларның һәр төркеменә аеруча квалификацияле белгечләр (эшчеләр) арасыннан остазлар беркетә;

2.3.9. Предприятиедә дуаль укыту программасын тормышка ашыруны тәэмин итә һәм дуаль укытуны үткәрү өчен шартлар тудыра;

2.3.10. Дуаль укытуны үткәрү чорында Укучыларны Предприятиегә алып килү, тукландыру, законнар нигезендә билгеләнгән нормативлар буенча махсус кием (форма), җитештерү чаралары, чыгым материаллары, яшәү урыны (кирәк булганда һәм мөмкинлек булганда) белән тәэмин итә;

2.3.11. Дуаль укыту максатлары һәм бурычлары нигезендә Укучыларга, законнар белән саклана торган сердән гыйбарәт мәгълүматтан тыш, гамәли материаллар һәм процесслардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итә;

2.3.12. Укучылар өчен Предприятиедә дуаль укыту үтүнең санитария кагыйдәләренә, хезмәтне саклау, яшәү иминлеге һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләренә җавап бирә торган куркынычсыз шартларны тәэмин итә;

2.3.13. Остаз тарафыннан дуаль укыту программасының, вазыйфаи тәгълимнамәнең һәм бурычларның үтәлүен тәэмин итә (шул исәптән Укучыларның җитештерү процессында катнашуын, Укучыларга күрсәтмәләр бирүне үткәрүне оештыру буенча);

2.3.14. Белем бирү оешмасы белән берлектә дуаль укыту процессында Укучы үзләштергән УһБ ФДБС һәм уку дисциплиналарының һәм һөнәри модульләрнең эш программалары нигезендә эшче һөнәре (белгечлеге) буенча гомуми һәм һөнәри компетенцияләрен бәяләү процедурасын оештыра;

2.3.15. Ел саен агымдагы елның 1 ноябренә кадәр Белем бирү оешмасының узган уку елына дуаль укыту үткәрү турында еллык хисабын килештерә.

2.4. Белем бирү оешмасының гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы:

2.4.1. Ел саен, агымдагы елның 1 июненә кадәр Белем бирү оешмалары тарафыннан Предприятиеләрдә дуаль укыту оештыру өчен белгечлекләр һәм һөнәрләр исемлеген билгели;

2.4.2. Дуаль укыту программасын, еллык календарь графигын, белем бирү процессын тәэмин итү буенча чаралар планын килештерә;

2.4.3. Укучының УһБ ФДБС, уку планы һәм укыту дисциплиналары һәм һөнәри модульләрнең эш программаларына ярашлы рәвештә тулы күләмдә белем алу өлешендә дуаль укытуны тормышка ашыруга агымдагы мониторинглауны башкара;

2.4.4. Белем бирү оешмасының дуаль укыту үткәрү турында еллык хисабын карап тикшерә.

---

Татарстан Республикасының урта
һөнәр белеме бирү программаларын
тормышка ашыручы һөнәри белем бирү
оешмаларында укучыларны дуаль
укытуны гамәлгә ашыру тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

**ДУАЛЬ УКЫТУНЫ ОЕШТЫРУ ТУРЫНДА ШАРТНАМӘ**

____________ шәһәре 20___ел, «___»____________

__________________________________________ урта һөнәр беләменең һөнәри

(белем бирү оешмасы исеме)

белем бирү оешмасы, алга таба «Белем бирү оешмасы» дип атала, ____________________________________________________ йөзендә,

(вазыйфасы, Ф.И.Ат.и.)

____________________________________________ нигезендә эш итүче, бер яктан һәм ____________________________________________, алга таба «Предприятие» дип атала,

(предприятие, оешма исеме)

____________________________________________________йөзендә,

(вазыйфасы, Ф.И.Ат.и.)

_______________________________нигезендә эш итүче, алга таба «Яклар» дип атала,

түбәндәгеләр турында әлеге Шартнамәне төзеделәр.

1. ШАРТНАМӘ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Яклар Белем бирү оешмасының ________ курсында укуның йөреп уку формасында Укучыларны дуаль укытуны бергәләп оештыру һәм гамәлгә ашыру йөкләмәсе алалар, Предприятиедә дуаль укыту процессында аларга ______________ статусы бирелә.

1.2. Укучыларның ________________________ әзерлек юнәлеше (белгечлеге, һөнәре) буенча федераль дәүләт белем бирү стандарты нигезендә урта һөнәри белемнең һөнәр белеме бирү программаларын сыйфатлы үзләштерүе, шулай ук Белем бирү оешмасында һәм Предприятиенең ____________________________ бүлекчәләрендә ________________________ өлкәсендә эшләүнең гамәли күнекмәләрен алуы дуаль укытуның максаты булып тора.

2. ЯКЛАРНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Белем бирү оешмасы түбәндәгеләргә бурычлы:

2.1.1. Предприятие белән берлектә дуаль укыту программасын, һөнәр (белгечлек) буенча укыту эш планын, еллык календарь графигын, белем бирү процессын тәэмин итү буенча чаралар планын эшләргә;

2.1.2. Предприятие белән дуаль укытуны үткәрү вакытларын һәм Предприятиегә җибәрелүче Укучыларның исемлек составын килештерергә;

2.1.3. Укучы һәм Предприятие арасында дуаль укыту турында укучылар шартнамәләрен төзергә ярдәм итәргә;

2.1.4. Дуаль укыту программасын тормышка ашыруны; урта һөнәри белемнең федераль дәүләт белем бирү стандарты, укыту планы һәм дуаль укыту программасы нигезендә Укучының тулы күләмдә белем алуын; студент квалификация имтиханын уңышлы тапшырган очракта квалификация дәрәҗәсе турында документ (таныклык) бирүне (әгәр урта һөнәри белемнең федераль дәүләт белем бирү стандарты белән һөнәри эшчәнлек төрләренең берсе кысаларында урта һөнәри белемнең төп һөнәр белеме бирү программасы модулен өйрәнү нәтиҗәләре буенча эшче һөнәрен үзләштерү каралган булса); Предприятиедә гамәлдә булган эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләренең, хезмәтне саклау, яшәү иминлеге һәм янгын куркынычсызлыгы һәм Предприятиедә гамәлдә булган бүтән локаль актлар таләпләренең, Предприятие милкеннән файдалану буенча таләпләрнең үтәлешен тәэмин итәргә;

2.1.5. Үзенә бирелгән вәкаләтләр кысаларында кураторның (производствода укыту остасы яки укытучының) урта һөнәри белемнең федераль дәүләт белем бирү стандартын, дуаль укыту программасын, уку дисциплиналарының һәм һөнәри модульләрнең эш программаларын, вазыйфаи тәгълимнамәләр һәм бурычларны тормышка ашыруны тәэмин итәргә;

2.1.6. Предприятие белән берлектә урта һөнәри белемнең федераль дәүләт белем бирү стандарты һәм дуаль укыту процессында формалашкан Укучыларның уку дисциплиналарының һәм һөнәри модульләрнең эш программалары нигезендә эшче һөнәре (белгечлек) буенча Укучыларның гомуми һәм һөнәри компетенцияләрен бәяләү процедурасын оештырырга;

2.1.7. Агымдагы елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча Белем бирү оешмасын гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органына тапшыру өчен узган уку елында дуаль укыту үткәрү турында еллык хисапны Предприятие белән килештерергә.

2.2. Предприятие түбәндәгеләргә бурычлы:

2.2.1. Белем бирү оешмасы белән берлектә дуаль укыту программасын, һөнәр (белгечлек) буенча укыту эш планын, еллык календарь графигын, белем бирү процессын тәэмин итү буенча чаралар планын эшләргә;

2.2.2. Белем бирү оешмасы белән дуаль укытуны үткәрү вакытларын һәм Предприятиегә җибәрелүче Укучыларның исемлек составын килештерергә;

2.2.3. Белем бирү оешмасы белән килештерелгән санда һәм вакытларда Укучыларны укырга кабул итәргә;

2.2.4. Укучы (укучылар) белән дуаль укыту турында укучылар шартнамәләрен төзергә;

2.2.5. Дуаль укыту программасын тормышка ашыруны; урта һөнәри белемнең федераль дәүләт белем бирү стандарты, укыту планы һәм дуаль укыту программасы нигезендә Укучының тулы күләмдә белем алуын; Предприятиедә Укучылар өчен дуаль укыту үтүнең санитария кагыйдәләренә, хезмәтне саклау, яшәү иминлеге һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләренә җавап бирә торган куркынычсыз шартларын тәэмин итәргә; Укучыларга Предприятиедә дуаль укыту үтү турында документ бирүне:_______________________________.
(документ исеме)

2.2.6. Укучыларны дуаль укыту программасының һәр юнәлеше буенча эштә гамәли белемнәргә һәм алымнарга өйрәтү өчен аларның һәр төркеменә аеруча квалификацияле белгечләр (эшчеләр) арасыннан остазлар беркетергә;

2.2.7. Дуаль укытуны үткәрү чорында Укучыларны Предприятиегә алып килү, тукландыру, законнар нигезендә билгеләнгән нормативлар буенча махсус кием (форма), житештерү чаралары, чыгым материаллары, яшәү урыны (кирәк булганда һәм мөмкинлек булганда) белән тәэмин итәргә;

2.2.8. Укучыларга, законнар белән сакланыла торган сердән гыйбарәт мәгълүматтан тыш, гамәли материаллар һәм процесслардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итәргә;

2.2.9. Остаз тарафыннан дуаль укыту программасының, вазыйфаи тәгълимнамәнең һәм бурычларның үтәлүен тәэмин итәргә, шул исәптән Укучыларның житештерү процессында катнашуын, Укучыларга куркынычсызлык техникасы буенча күрсәтмәләр бирүне үткәрүне оештыру буенча;

2.2.10. Белем бирү оешмасы белән берлектә урта һөнәри белемнең федераль дәүләт белем бирү стандарты һәм дуаль укыту процессында формалашкан Укучыларның уку дисциплиналарының һәм һөнәри модульләрнең эш программалары нигезендә эшче һөнәре (белгечлек) буенча Укучыларның гомуми һәм һөнәри компетенцияләрен бәяләү процедурасын оештырырга;

2.2.11. Предприятиедә билгеләнгән тәртиптә дуаль укытуны тормышка ашыру кысаларында укыту процессын үткәрү буенча хезмәткәрләр (остазлар) хезмәтен түләргә;

2.2.12. Ел саен, агымдагы елның 1 ноябренә кадәр Белем бирү оешмасының узган уку елында дуаль укыту үткәрү турында еллык хисабын килештерергә.

## 3. ШАРТНАМӘНЕҢ ГАМӘЛДӘ БУЛУ ВАКЫТЫ

3.1. Әлеге Шартнамә Яклар имзалаган көннән соң көченә керә.

3.2. Шартнамә ______________ ел дәвамында гамәлдә була.

3.3. Шартнамәгә өстәмә шартлар һәм үзгәрешләр _____________көненнән башлап календарь көннәрендә исәпләнүче ун көн эчендә Яклар тарафыннан карап тикшерелә һәм өстәмә шарнамәләр белән рәсмиләштерелә.

3.4. Шартнамәгә өстәмәләр аның аерылгысыз өлеше булып тора.

## 4. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

4.1. Яклар әлеге Шартнамә буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

4.2. Яклар әлеге Шартнамә буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыктан, әгәр җиңә алмас көч шартлары нәтиҗәсе булса, азат ителәләр.

## 5. БАШКА ШАРТЛАР

5.1. Әлеге Шартнамәдә җайга салынмаган сораулар Россия Федерациясе законнары нигезендә хәл ителәләр.

5.2. Әлеге Шартнамә шартларын үтәү процессында килеп чыга торган бәхәсләр һәм каршылыклар Якларның килешүе буенча хәл ителә.

5.3. Шартнамә ике нөсхәдә төзелгән, аларның һәркайсы бер үк төрле юридик көчкә ия.

## 6. ЯКЛАРНЫҢ ЮРИДИК АДРЕСЛАРЫ ҺӘМ РЕКВИЗИТЛАРЫ

| | |
|---|---|
| **Белем бирү оешмасы (исеме)** | **Предприятие (исеме)** |
| Адрес: ______________________ | Адрес: ______________________ |
| Банк реквизитлары: _______ | Банк реквизитлары: _______ |
| Җитәкче: | Җитәкче: |
| ___________________________ | _________________________ |
| (имза, Ф.И.Ат.и.) | (имза, Ф.И.Ат.и.) |
| М.У. | М.У. |

Татарстан Республикасының урта һөнәр белеме бирү программаларын тормышка ашыручы һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны дуаль укытуны гамәлгә ашыру тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

**ДУАЛЬ УКЫТУ ТУРЫНДА УКУЧЫ ШАРТНАМӘСЕ**

____________ шәһәре 20___ел, «___»____________

Предприятие (оешма) ______________________________________________,
алга таба «Предприятие» дип атала, (предприятие, оешма исеме)
______________________________________________йөзендә,

(вазыйфасы, житәкче Ф.И.Ат.и.)
_______________________________нигезендә эш итүче һәм гражданин
___________________, ___________________________________________ студенты,

(Ф.И.Ат.и.) (белем бирү оешмасы исеме)
алга таба «Укучы» (укучының законлы вәкиле) дип атала, үз мәнфәгатьләрендә һәм үз исеменнән эш итүче (Укучы мәнфәгатьләрендә эш итүче), бергә әйткәндә «Яклар» дип атала, түбәндәгеләр турында әлеге Шартнамәне төзеделәр.

## 1. ШАРТНАМӘ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Әлеге Шартнамә нигезендә Предприятие дуаль укытуны оештыра, ә Укучы _________________________________________________ юнәлеше буенча дуаль укыту программасы нигезендә һөнәр (белгечлек) үзләштерү максатларында укый.

1.2. Дуаль укыту Предприятиедә Предприятие һәм урта һөнәри белемнең һөнәр белеме бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмасының (алга таба – Белем бирү оешмасы) гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы белән килештерелгән____________________________________________

(әлеге һөнәре/белгечлеге коды һәм исеме)
федераль дәүләт белем бирү стандарты ______ ел дәвамында гамәлгә ашырыла.

Дуаль укыту башлану: _______________;

Дуаль укыту тәмамлану: _____________.

Дуаль укыту формасы: йөреп уку, көндезге.

1.3. Уку елы дәвамында Укучыга ике тапкырдан да ким булмаган каникуллар билгеләнә, аларның гомуми дәвамлылыгы һәр белгечлек (һөнәр) буенча федераль дәүләт белем бирү стандарты белән билгеләнә.

Каникулларның башлану һәм тәмамлану вакытлары Предприятие белән килештерелә.

## 2. ЯКЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Предприятие бурычлы:

2.1.1. Эштә гамәли белемнәргә һәм алымнарга өйрәтү өчен аеруча квалификацияле белгечләр (эшчеләр) арасыннан Укучыга остаз беркетергә;

2.1.2. Укучыны Предприятиенең эчке тәртип кагыйдәләре, санитар, янгынга каршы һәм бүтән гомуммәҗбүри нормалар һәм кагыйдәләр белән таныштырырга;

2.1.3. Дуаль укытуны үткәрү һәм ике арадагы һәм йомгаклау аттестациясен үткәрү чорында әлеге Шартнамәдә күрсәтелгән һөнәрне (белгечлекне) үзләштерү өчен кирәкле уку чараларын, җиһазларны, чыгым материалларын Укучыга бушлай бирергә;

2.1.4. Предприятиедә уку дәверендә Укучыны гамәлдәге нормативлар буенча туклану, махсус кием (форма) белән, җитештерү чаралары, чыгым материаллары белән тәэмин итәргә;

2.1.5. Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән бурычларны үтәргә.

2.2. Укучы бурычлы:

2.2.1. Куратор (укытучы, производствода укыту остасы), остаз билгели торган федераль дәүләт белем бирү стандартын үзләштерү кысаларында дәресләргә йөрергә һәм биремнәр башкарырга; федераль дәүләт белем бирү стандарты нигезендә сайлап алынган һөнәр (белгечлек) буенча төп һөнәри белем бирү программасын тырышып үзләштерергә;

2.2.2. Дуаль укыту вакытында Предприятиенең эчке тәртип кагыйдәләрен һәм бүтән локаль норматив актларын, шул исәптән хезмәтне саклау тармагындагы актларны үтәргә; Предприятие мөлкәтен сакчыл тотарга;

2.2.3. Укытучының (производствода укыту остасының) укуга һәм җитештерү процессына кагылышлы күрсәтмәләрен үтәргә;

2.2.4. Предприятиенең коммерциячел сере булган белешмәләрне таратмаска.

2.3. Предприятие хокуклы:

2.3.1. Һөнәри укыту чыгымнарының бюджеттан тыш өлешен каплау, шулай ук Укучыга матди ярдәм күрсәтүне көчәйтү максатларында конкурс нигезендә Укучыга белем бирү заемы бирергә;

2.3.2. Вакансияләр булганда һәм законнар нигезендә эшкә урнашуга таләпләрне үтәгәндә Белем бирү оешмасын тәмамлаганнан соң Укучыны эшкә урнаштырырга.

2.4. Укучы хокуклы:

2.4.1. Конкурс нигезендә Предприятиедән белем бирү заемын алуга дәгъва итәргә;

2.4.2. Предприятиедә вакансияләр булганда һәм законнар нигезендә эшкә урнашуга таләпләрне үтәгәндә Белем бирү оешмасын тәмамлаганнан соң ____________ чорына Предприятие белән хезмәт шартнамәсе төзергә.

## 3. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

3.1. Яклар әлеге Шартнамәдә каралган бурычларны үтәмәгәндә яки тиешле дәрәҗәдә үтәмәгәндә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

3.2. Укучы үзе турыдан-туры Предприятиегә китергән гамәлдәге зыян өчен дә, шулай ук законнарда билгеләнгән тәртиптә Укучының гаебе булганда ул бүтән затларга китергән зыянны каплау нәтиҗәсендә предприятиегә китерелгән зыян өчен дә матди җаваплы була.

## 4. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

4.1. Шартнамә _____ нөсхәдә төзелде, аларның һәркайсы бер үк төрле юридик көчкә ия.

4.2. Шартнамә Яклар тарафыннан имзаланган көннән көченә керә һәм аның буенча Якларның үз бурычларын үтәве тәмамланганга кадәр гамәлдә була.

4.3. Әлеге Шартнамәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр язмача рәвештә рәсмиләштереләләр, барлык Яклар тарафыннан имзалана һәм әлеге Шартнамәнең аерылгысыз өлеше булып тора.

4.4. Шартнамә буенча килеп чыккан бәхәсләр сөйләшүләр нигезендә хәл ителә. Килешү ирешелмәгәндә бәхәсләр законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

4.5. Шартнамәдә җайга салынмаган сораулар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

4.6. Әлеге Шартнамәнең гамәлдә булуы туктатылу аның буенча Якларның бурычлары туктатылуга китерә, әмма әгәр Шартнамә шартларын үтәгәндә бозулар булганда, аның өчен Якларны җаваплылыктан азат итми.

## 5. ЯКЛАРНЫҢ АДРЕСЛАРЫ ҺӘМ РЕКВИЗИТЛАРЫ

| **Предприятие** | **Укучының законлы вәкиле** | **Укучы** |
|---|---|---|
| | ____________________ (Ф.И.Ат.и.) | ____________________ (Ф.И.Ат.и.) |
| Почта адресы | Паспорт серия ____№ бирелгән | Паспорт серия ____№ бирелгән |
| Банк реквизитлары | ____________________ (бирелү вакыты һәм урыны) | ____________________ (бирелү вакыты һәм урыны) |
| ____________________ (вазыйфа исеме) | Гамәлдәге яшәү адресы: | Гамәлдәге яшәү адресы: |
| ____________________ (җитәкче Ф.И.Ат.и.) | ____________________ | ____________________ |
| ____________________ (имза) | ____________________ (имза) | ____________________ (имза) |
| 20__ел, «__»______ М.У. | 20__ел, «__»______ | 20__ел, «__»______ |